**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 48 балл**

## I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).

1. Фәлсәфи шигырьгә хас үзенчәлекләрне Дәрдемәнд иҗаты мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).
2. Аның шигырьләре кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

## II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).

1. Оренбург өлкәсе Акман авылы – Казан – Әстерхан – Уфа. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).
2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).
3. С.Рәмиевнең лирик героена нинди сыйфатлар хас? (10 балл).
4. С.Рәмиевнең әсәрләрендә үз чорына хас нинди фикерләр урын ала? (10 балл).

## III. Иҗади эш (10 балл).

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *йоклый, уянам, кебек, таң, бер, уйланам, вакыты, тиле, татар, мин, уянам, тик, йокысыз, да, үзем*.